**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Туймәт авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге
составына керүче Туймәт торак пунктында

**18 октябрь 2024 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлегенең Туймәт торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2025 елда Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Туймәт торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш.

2. Алынган чараларны түбәндәгеләргә җибәрергә:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, Туймәт авылында тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу,

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен башка билгеләнештәге җиһазларны ремонтлау** (Туймәт торак пунктында урамнарны яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Туймәт торак пунктының Яңа урамында вак таш сатып алу, урам-юл челтәрен салу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу)

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге башлыгы урынбасары Х.Х. Сәхапова